**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__05.05.2023__ г. Казань **№_____62од_________**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында Татарстан Республикасы юстиция министрының 2020 елның 26 декабрендәге157од номерлы боерыгы белән расланган нигезләмәгә (2022 елның24 маендагы 106од,2023 елның 17 февралендәге21од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс дәүләт граждан хезмәте (алга таба – гражданлык хезмәте) вазыйфасын биләүгә дәгъвачыларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, аларның гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән башка квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүдән һәм мондый бәяләү һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданны яки гражданлык хезмәткәрен дәгъвачылар арасыннан гражданлык хезмәте вазифасына билгеләү өчен  сайлап алудан гыйбарәт.»;

1.7 пунктта:

өченче абзацта «кече вазифалар төркеменә» сүзләрен «кече төркем вазыйфаларына» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«федераль законнарда каралган башка очракларда.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Граждан (граждан хезмәткәре) конкурста катнашуга кертелми:

а) һөнәри белем дәрәҗәсенә квалификация таләпләренә, гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш, әзерлек юнәлешенә туры килмәү сәбәпле;

б) белгечлеккә квалификация таләпләренә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең эреләндерелгән төркемнәренә), кабат һөнәри әзерлекнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә (гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре белән мондый таләпләр каралган очракта) туры килмәү сәбәпле;

в) гражданлык хезмәтенә керү һәм аны узу белән бәйле һәм Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында законнары белән билгеләнгән чикләүләр белән бәйле рәвештә.»;

3.4 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«белем һәм (яки) квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук гражданның теләге буенча гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турындагы нотариаль яки хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган документларның күчермәләре;»;

4.1 пунктта «һөнәри һәм шәхси сыйфатлары» сүзләрен «һөнәри дәрәҗә, һөнәри һәм шәхси сыйфатлары» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Министр карары буенча гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына карата гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентларында белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең эреләндерелгән төркемнәренә), кабат һөнәри әзерлекнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә квалификация таләпләре билгеләнергә мөмкин.»;

4.5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«гражданның (граждан хезмәткәренең) һөнәри белем дәрәҗәсенә, гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә, һөнәри дәрәҗәгә, шулай ук министрның тиешле карары булганда - белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең эреләндерелгән төркемнәренә), кабат һөнәри әзерлекнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә туры килүен тикшерү.»;

4.11 пунктның өченче абзацына «конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү» сүзләре алдына «профессиональ дәрәҗәдәге» сүзләрен өстәргә;

4.12 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.12. Конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе кандидатларны белем һәм (яки) квалификация, гражданлык яки башка дәүләт хезмәте үтү, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында алар тапшырган документлар нигезендә, шулай ук кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәгән ысулларын кулланып, кандидат дәгъва итә торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле сораулар буенча индивидуаль әңгәмәне, анкета тутыруны, төркемле дискуссияләр үткәрү, реферат язу яки тест үткәрүне кертеп, конкурс процедуралары нигезендә бәяли. Конкурс үткәрелә торган вазифаларның төркеменә һәм

категориясенә карап, төрле ысуллар кулланылырга мөмкин. Шул ук вакытта тест узу һәм кандидат белән индивидуаль әңгәмә барлык кандидатлар өчен мәҗбүри булып тора.».

1. Бу боерыкның гамәлдә булуы 2023 елның 29 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Министр Р.И. Заһидуллин